**Татарстан Республикасы**
**дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2007 елның 5 июлендә
кабул ителде

*(2011 елның 10 октябрендәге 75-ТРЗ, 2015 елның 7 октябрендәге 70-ТРЗ, 2015 елның 9 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы, 2016 елның 9 июлендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә )*

Әлеге Закон Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтеннән рациональ һәм нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү, шулай ук аның сакланышын тикшереп торуны оештыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү тәртибен билгели.

1 статья. **Әлеге Законның гамәлдә булу даирәсе**

1. Әлеге Законның гамәлдә булуы түбәндәгеләр белән идарә итүгә бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый:

акцияләрдән тыш, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары һәм башка финанс активлары белән;

федераль, муниципаль, хосусый һәм башка рәвешләрдәге милек объектлары белән;

Татарстан Республикасының җир, су һәм башка табигать ресурслары белән.

2. Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру хосусыйлаштыру турындагы законнар белән җайга салына.

2 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү**

1. Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте (алга таба – дәүләт мөлкәте) белән идарә итү һәм эш итү (алга таба – идарә итү) түбәндәге максатларда гамәлгә ашырыла:

1) дәүләт мөлкәте белән нәтиҗәле идарә итү нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен арттыру;

2) дәүләт мөлкәте структурасын оптимальләштерү;

3) дәүләт мөлкәтеннән Татарстан Республикасы икътисадына инвестицияләр җәлеп итү чарасы буларак файдалану;

4) дәүләт мөлкәтенең ликвидлылыгын арттыру;

5) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының үз функцияләрен гамәлгә ашыруын тәэмин итү.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары дәүләт мөлкәтенә карата үз компетенцияләре чикләрендә законнарга каршы килмәүче һәм башка затларның хокукларын һәм закон белән саклана торган мәнфәгатьләрен бозмаучы гамәлләр кылырга хокуклы, шул исәптән:

1) дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы дәүләт милкеннән аерып алырга;

2) дәүләт мөлкәтен арендага, залогка тапшыруны гамәлгә ашырырга һәм аны башка ысуллар белән йөкләргә;

3) дәүләт мөлкәтен башка физик һәм юридик затлар мөлкәте белән берләштерергә;

4) дәүләт мөлкәтен ышанычлы идарәгә тапшырырга;

5) дәүләт мөлкәте белән башкача эш итәргә.

3 статья. **Дәүләт мөлкәте белән идарә итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Дәүләт мөлкәте белән идарә итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы:

1) законнар белән җайга салуны гамәлгә ашыра;

2) дәүләт мөлкәте белән идарә итүнең һәм эш итүнең билгеләнгән тәртибен үтәүне тикшереп тора.

2. Дәүләт мөлкәте белән идарә итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты:

1) шушы өлкәдә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен билгели;

2) дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү буенча, шул исәптән әлеге Законның $12^1$ статьясындагы нигезләмәләрне гамәлгә ашырганда, үз компетенциясе чикләрендә карарлар кабул итә; *(2 пункт 2011 елның 10 октябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3. Дәүләт мөлкәте белән идарә итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

1) әлеге Законны үтәү йөзеннән норматив хокукый актлар бастырып чыгара;

2) түбәндәге карарларны кабул итә:

Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре, акционер җәмгыятьләр төзү турында; *(икенче абзац 2015 елның 7 октябрендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

дәүләт мөлкәте белән эш итү турында;

дәүләт мөлкәте белән тиешенчә идарә итүне тәэмин итү турында;

3) әлеге Законда каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

4. Мөлкәт мөнәсәбәтләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (алга таба - башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы) законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы исеменнән дәүләт мөлкәте белән идарә итү буенча милекче вәкаләтләрен гамәлгә ашыра, шул исәптән әлеге Законда һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда дәүләт мөлкәте белән эш итү турында карарлар кабул итә.

Дәүләт мөлкәте белән идарә итү мәсьәләләре буенча башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы вәкаләтләре шушы орган турындагы нигезләмә белән билгеләнә.

5. Дәүләт мөлкәте белән идарә итү өлкәсендә тармак компетенциясенең башкарма хакимият органнары:

1) Татарстан Республикасы бюджет учреждениеләрен гамәлгә куючы булып торалар;

2) Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләрен төзү, үзгәртеп төзү, ликвидацияләү, хосусыйлаштыру турында инициатива белән чыгалар;

3) Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен төзү, үзгәртеп төзү, ликвидацияләү турында инициатива белән чыгалар;

4) үз компетенциясе чикләрендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

4 статья. **Дәүләт мөлкәтен исәпкә алу**

1. Татарстан Республикасының милек хокукындагы хуҗалык җәмгыятьләренең күчемсез мөлкәте, акцияләре (устав капиталындагы өлешләр) Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрында исәпкә алынырга тиеш.

Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрында исәпкә алынырга тиеш күчемле мөлкәт объектларының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан аерым төрләре билгеләнергә мөмкин.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрын алып бару тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

5 статья. **Татарстан Республикасы казнасының күчемсез мөлкәте белән идарә итү**

1. Татарстан Республикасы казнасының күчемсез мөлкәте составына Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренә хуҗалык алып бару хокукында яисә оператив идарә итү хокукында һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә оператив идарә итү хокукында беркетелмәгән Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге күчемсез мөлкәт объектлары керә, шул исәптән:

1) Татарстан Республикасының ликвидацияләнгән дәүләт унитар предприятиеләренең һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең мөлкәт комплекслары;

2) юридик затлар яки индивидуаль эшкуарлар арендага яисә ышанычлы идарәгә алган күчемсез мөлкәт;

3) күчемсез мөлкәт объектларына уртак өлешле милек хокукындагы Татарстан Республикасы өлеше;

4) Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренең һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең хуҗалык карамагыннан яисә оператив идарә итүеннән законнарда билгеләнгән очракларда тартып алынган күчемсез мөлкәт;

5) законнар нигезендә бүтән күчемсез мөлкәт.

2. Татарстан Республикасы казнасының күчемсез мөлкәте белән идарә итү, аның сакланылышын һәм максатчан кулланылышын исәпкә алу һәм тикшереп тору Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла. *(2 өлеш 2016 елның 9 июлендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

3. Татарстан Республикасы казнасы күчемсез мөлкәтенең сакланылышын һәм максатчан кулланылышын тикшереп тору башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы тарафыннан турыдан-туры яисә махсуслашкан оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

6 статья. **Хуҗалык җәмгыятьләренең (ширкәтләренең) устав (тупланма) капиталларындагы акцияләр, өлешләр белән идарә итү**

1. Татарстан Республикасының милек хокукындагы хуҗалык җәмгыятьләре (ширкәтләре) устав капиталларындагы акцияләр, өлешләр белән идарә итү башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Әгәр законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы законнар нигезендә Татарстан Республикасы тарафыннан төзелгән хуҗалык җәмгыятьләренең катнашучысы һәм гамәлгә куючысы буларак эш итә.

3. Устав капиталларында Татарстан Республикасының милек хокукына карый торган акцияләр, өлешләр булган хуҗалык җәмгыятьләре (ширкәтләре) белән идарә итүдә катнашу хуҗалык җәмгыятьләренең (ширкәтләренең) идарә һәм контроль органнарында дәүләт вәкилләре аша законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

7 статья. **Дәүләт мөлкәтен түләүсез файдалануга тапшыру** *(статья 2011 елның 10 октябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

Дәүләт мөлкәте Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына, юридик һәм физик затларга сәламәтлек саклауны, мәгарифне, халыкка социаль хезмәт күрсәтүне, физик культураны һәм спортны, мәдәниятне үстерүгә; мәдәни кыйммәтләрне, гражданнар оборонасы, торак-коммуналь хуҗалык объектларын саклауга; юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә; Татарстан Республикасы торак фонды, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына, терлек каберлекләренә, гидротехник корылмаларга хезмәт күрсәтүгә бәйле максатларга, әгәр федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында дәүләт мөлкәте белән мондый алым ярдәмендә һәм әлеге статьяда күрсәтелгән максатларда эш итүне тыя торган нигезләмәләр булмаса, түләүсез файдалануга тапшырылырга мөмкин.

8 статья. **Дәүләт мөлкәтен арендага бирү** *(статья 2011 елның 10 октябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

1. Дәүләт мөлкәтен арендага бирүчеләр түбәндәгеләр:

1) законнарда билгеләнгән очракларда үз вәкаләтләре чикләрендә казна мөлкәтенә һәм башка мөлкәткә карата башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы;

2) үзләренә хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән мөлкәткә карата Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре;

3) үзләренә оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәткә карата Татарстан Республикасы казна предприятиеләре һәм дәүләт учреждениеләре;

4) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә дәүләт мөлкәтен арендага бирү хокукына ия затлар.

2. Дәүләт мөлкәте өчен аренда түләве күләмен билгеләү тәртибе, шулай ук аренда түләве буенча ташламалар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана. (*2 өлеш 2015 елның 9 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

9 статья. **Дәүләт мөлкәтен залогка тапшыру**

1. Татарстан Республикасы казнасын тәшкил итә торган мөлкәтне залогка тапшыру түбәндәгеләрне тәэмин итү өчен башкарылырга мөмкин:

Татарстан Республикасы йөкләмәләрен;

үтәлешләрендә Татарстан Республикасы кызыксынган Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре, устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше булган хуҗалык җәмгыятьләре йөкләмәләрен.

2. Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе хуҗалык алып бару хокукында үзенә караган мөлкәтне залогка башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы рөхсәте белән бирергә хокуклы.

Дәүләт мөлкәтен залогка тапшыруга рөхсәт бирү тәртибе башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.

10 статья. **Дәүләт мөлкәтен ышанычлы идарәгә тапшыру**

1. Дәүләт мөлкәтен ышанычлы идарәгә тапшыру турында карарны башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы кабул итә. Әгәр шартнамәне гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын куллануны таләп итсә, карар проекты Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс өлкәсендәге вәкаләтле органы белән килештерелергә тиеш.

2. Башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы ышанычлы идарәне гамәлгә куючы булып тора.

3. Ышанычлы идарәче, үзенә тапшырылган мөлкәт белән ышанычлы идарәне башкарганда, әлеге мөлкәткә карата ышанычлы идарә шартнамәсе нигезендә бары

тик Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә генә теләсә нинди юридик һәм факттагы гамәлләрне башкарырга хокуклы.

11 статья. **Дәүләт мөлкәтен федераль һәм муниципаль милеккә тапшыру**

1. Дәүләт мөлкәтен федераль һәм муниципаль милеккә тапшыру федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүлешкәндә, федераль дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына беркетелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен, шулай ук законнарда каралган башка очракларда башкарыла.

2. Дәүләт мөлкәтен муниципаль милеккә тапшыру турында карарлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан яисә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты шундый вәкаләтләр бирсә, башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы тарафыннан кабул ителә.

3. Дәүләт мөлкәтен федераль һәм муниципаль милеккә тапшыру федераль дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары инициативасы белән гамәлгә ашырыла.

12 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге күчемсез мөлкәт объектларын инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бирү**

1. Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге күчемсез мөлкәт объектлары, шул исәптән тәмамланмаган төзелеш объектлары, инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында, шул исәптән, әгәр мондый эшчәнлек нәтиҗәсендә яңа күчемсез мөлкәт (яңа әйбер) төзелсә, бирелергә мөмкин.

2. Әлеге Закон кысаларында инвестиция эшчәнлеге дигәндә күчемсез мөлкәт объектына, реконструкция үткәрү һәм төзелеш тәмамлау өчен Татарстан Республикасының финанс чаралары җитәрлек булмаганда, реконструкция үткәрү, төзелеш тәмамлау, табыш алу һәм башка файдалы нәтиҗәгә ирешү максатларында күчемсез мөлкәт объектына карата башка гамәлләр кылу аңлашыла.

3. Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге күчемсез мөлкәт объектларын инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында бирү турындагы карар башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы тарафыннан кабул ителә.

$12^1$ статья. **Дәүләт мөлкәтен бүләк итү** *(статья 2011 елның 10 октябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде)*

Дәүләт мөлкәтен бүләк итү законнарда каралган очракларда һәм тәртиптә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

13 статья. **Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыкканнан соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан, Кремль
2007 елның 26 июле
№ 35-ТРЗ